**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Иске Казиле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

12 нче март 2021 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 нче елның 12 нче мартында булып узган гражданнар жыены нәтиҗәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең 2020 елның 9 декабрендәге 3 нче номерлы Иске Казиле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме:
1.) 2 пунктта “500 сум күләмендэ” сүзләрен “600 сум күләмендә” сүзләренә алмаштырырга;
2.) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 нчы пункт өстәргә:
6) торак пункт территорияләрен төзекләндерү (яңа ел чыршыларын бизэу очен уенчыклар сатып алу).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 138 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 73 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 73 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

**1.** Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге составына керүче Иске Казиле авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

**2**. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең 2020 елның 9 декабрендәге 3 нче номерлы Иске Казиле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карарга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү белән килешәсезме:
1.) 2 пунктта “500 сум күләмендэ” сүзләрен “600 сум күләмендә” сүзләренә алмаштырырга;
2.) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 нчы пункт өстәргә:
6) торак пункт территорияләрен төзекләндерү (яңа ел чыршыларын бизэу очен уенчыклар сатып алу)”-

соравы буенча карарны кабул ителгән дип таныpга.

**3.** 2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге территориясе, Иске Казиле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

1) Иске Казиле т. п. буенча юл-урам челтәрен төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;

2) Иске Казиле т. п. юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3) Иске Казиле т.п. территориясен чуп улэннэреннэн чистарту (чапкыч очен запас частлэр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

4) Иске Казиле т. п. да янгын гидрантларын тэртиптэ тоту (янгын гидрантларын, краннарны (җайланмаларны) кышка җылыту, люкларны кардан, боздан даими чистарту, язгы-җәйге янгын куркынычы чорына әзерлек һәм тикшерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

5) Иске Казиле т. п. зираты территориясен төзекләндерү (бункер сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

6) торак пункт территорияләрен төзекләндерү (яңа ел чыршыларын бизэу очен уенчыклар сатып алу).

**4.** Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
башлыгы: И.Х.Сәгдиев